ХЕЗМӘТ БАТЫР

хезмәт турында татар халык мәкальләре

ББК84.5(2Р-Тат)
Х42

Х $\frac{4803010200-074}{М132(03)-85}$ 205—85

© Татарстан китап нәшрияты, 1985.

Укымаган — ил бозар,
укыган — ил төзәр.

Эш сөймәсне ил сөймәс.

Буй белән түгел, уй белән.

Ир беләге тау җиңә.

Түзгән — тимерне дә өзгән.


Ир мактаныр, корал эшләр.

Буласы ир — алты яшендә башмын дияр,
булмас ир — алтмыш яшендә яшьмен дияр.

Кошның матурлыгы төсенә карап,
кешенең матурлыгы эшенә карап.

Эше эшкә охшамый, кулы эштән бушамый.

Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.

Я уңасың, я туңасың.

Итәгенә ут капса да кузгалмас.

Сәләтле сәнәк тотуыннан билгеле.

Уңган кешегә тау түзми.

Ялкауның сапламы озын.

Җитез кеше җир астыннан җиз энә табып алыр.

Карама беләккә, кара йөрәккә.

Бәрәү бар — аз эшли дә үз эшли,
берәү бар — күп эшли дә чүп эшли.

Кулыннан гөл генә таммый.

Матурлык туйда кирәк,
уңганлык көн дә кирәк.


Авыр эшкә беләк бар,
кыю эшкә йөрәк бар.

Булдыксыз — балтадан күрер.

Юнен тапкан — айга очар,
юньсез — җирдә абынып үләр.

Омтылган — зурга омтылыр,
омтылмаган — онытылыр.

Тәрәзәдән кергән ай яктысына ябышып
күккә менеп булмый.

Аннан ит тә юк, сөт тә юк.

Исәпкә бар, санга юк.

Эшләп үлмиләр, чирләп үләләр.

Ялкауның эше дә таркау.

Авырып торам димә,
иренеп торам диген.

Теле белән күктәге айны йөртә белгән,
кулы белән казандагы майны эретә
белмәгән.



ЯЗГЫ
БЕР көн
ЕЛ
ТУЙДЫра.

Эше барның ашы бар.
Эше юкның ашы юк.

Тимерне кызуында сук.

Эшләгән ашый, эшләмәгән башын кашый.

Иртәгеге эшеңне бүген уйлап куй.

Аяз көнне алма җыя, яңгыр көнне богыл коя.

Калган эшкә кар ява.

Эшләмәсәң эш көне, ни ашарсың кыш көне?

Эшләгән — тешләгән
эшләмәгән — кешнәгән.

Эшләмәгән ашамый,
ашамаган яшәми.

Аз кулны ашта күр,
күп кулны эштә күр.

Ашаганда колагың селкенсен,
эшләгәндә йөрәгең җилкенсен.

Агач
Җимеше
Белән,
адәм
эше
Белән.

Алма пеш, авызыма төш.

Эше каты, икмәге татлы.

Тырышлык бәхет китерер,
ялкаулык ачтан үтерер.

Ялкау бер эш эшли белә —
чалкан ятып мышный белә.

Ялкау әйткән: — Бүген ял итим дә иртәгә
ныклап эшләрмен!
Тырыш әйткән: — Бүген тырышып эшлим дә
иртәгә ял итәрмен.

Ялкау егет картларга охшар,
җегәрле карт егетләргә охшар.

Җиңелне өмет иткән, тормышы кире
киткән.

Эшең каты булса, тешеңә йомшак булыр.

Кем эшләми, шул ашамый.

Тирләп эшләсәң, тәмләп ашарсың.

Эш беткәч, уйнарга ярый.

Эшләнгән эш иргә кот,
яхшы эшләнсә илгә кот.

Тыйнакның
кулы эшләр,
мактанчыкның
теле эшләр

Тел белән тегермән тарттырып була,
тонлы булып булмый.

Гали — Вәлигә, Вәли Галигә ышана.

Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән
кем салыр?

Эшем күп, вакытым тар,
эт дагалыйсым бар.

Эшле кеше эшен карый,
эрәмтамак тешен казый.

Әзергә хәзер.

Аш дигәндә — җан-фәрман,
эш дигәндә — юк дәрман.

Аш янында бүре күк,
эш янында шүре күк.

Эшкә булса — алла, башым,
ашка булса — кайда кашыгым?

Комнан аркан ишеп,
күлне күккә асып булмый.



Эш батыры — ил батыры.

Эш күрсәткән ирне ил онытмас.

Данның төбе — хөрмәт,
хөрмәтнең төбе — хезмәт.

Хезмәте барның хөрмәте бар.

Авыр йөкне ат тарта,
авыр эшне ир тарта.

Яшьлегең тырыш булса, картлыгың
тыныч булыр.



хезмәт иясе –
хөрмәт иясе!

15 тиен.

Художнигы Татьяна Литвинова

МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН

На общественных началах составил и редактировал
Нурмухаметов Тахир Мирзагалямович

ТРУД — БОГАТЫРЬ

Татарские народные пословицы о труде

(на татарском языке)

Җәмәгать эше тәртибендә төзеде һәм редакцияләде **Т. Нурмөхәммәтов.** Художество редакторы **Ф. Хасьянова.** Техник редакторы **С. Әхмәтҗанова.** Корректоры **М. М. Гайфетдинова.** ИБ № 3704. Наборга бирелде 26.11.84. Басарга кул куелды 19.03.85. Формат $60 \times 90^{1}/_{8}$. 100 гр. офсет кәгазе. Гарнитура школьная. Печать офсетная. Басма табагы 2,0. Усл. кр. отт. 9,0. Учетн.-изд. табагы 1,7. Тираж 15 000. Заказ Б-733. Бәясе 15 тиен. Татарстан китап нәшрияты. 420084, Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. 420084, Казань, ул. Баумана, 19. Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт крмитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.

КАЗАН · ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ · 1985